**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-457 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-76 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-507 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-216 номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге ПУ-531 номерлы, 2020 елның 10 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2021 елның 26 августындагы ПУ-675 номерлы, 2021 елның 12 ноябрендәге ПУ-871 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 10 маендагы 286 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Л.А. Гайнетдинованы, Р.А. Галиевны, Т.В. Кәримуллинны, А.В. Молевны, С.Н. Погодинны, Р.Җ. Хәбибуллинны, Д.З. Хәмәдишинны, И.Ш. Ханбиковны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Комиссия секретаре итеп раслап, Әлмиев Рамил Ринат улын – Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының оештыру эше секторы мөдирен;

Артемьев Артем Викторовичны – Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Балабанов Олег Ивановичны – «Транснефть-Прикамье» акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Беляев Юрий Михайловичны – Татарстан Республикасы хәрби комиссарын (килешү буенча);

Кадәмов Ирек Илгиз улы – Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Суржко Николай Владимировичны – Татарстан Республикасы граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Шакиров Фаяз Фәнил улын – Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 05 сентябрь
№ 688